# Унҗиденче ноябрь.
# Сишәмбе.

# Фонетик күнегү.

Шүрәле юлга чыга.

Бара, бара, чишмә тавышын ишетә: [шшшш]

Кошлар сайрый: [чут], [чут], [чут], [чут]

Җил исә: [жжжжж]

Бал кортлары тавышы ишетелә: [җҗҗжҗ]

Чебеннәр кушыла: [безззз]

Черкиләр оча: [тсссссс]

Алар Шүрәлене тешлиләр. Шүрәле елый: [әәәәәәә]

Әйдәгез, аларны куып җибәрик әле: [көөөөөөш]

Шүрәле сөенә: [үүүүүүүүүүү].

# Габдулла Тукай.

Габдулла Тукай – бөек шагыйрь. Ул бик күп шигырьләр, әкиятләр язган.

Аның әсәрләрен өлкәннәр дә, кечкенәләр дә бик яраталар.

Шагыйрьнең тормыш юлы бик авыр була. Габдулла Тукай әтисез-әнисез үсә. Ул барысы 27 ел яши.

26 нчы апрель – шагыйрьнең туган көне. Ул көнне Казанда шигырь бәйрәме була.

# Сорауларга җавап бир:

- Габдулла Тукай кем ул?
- Ул нәрсә язган?
- Ул ничә ел яшәгән?
- Шагыйрьнең туган көне кайчан?
- Шигырь бәйрәме нинди шәһәрдә була?
- Шагыйрьнең гаиләсе булганмы?

Гаилә

[Ғ А̊ Й Л Ә́]

Әни – мама,
әти – папа,
әби – бабушка,
бабай – дедушка,
абый – старший брат,
апа – старшая сестра,
эне – братишка,
сеңел – сестренка.

# Артык сүзне тап

**Әти, әни, әби, абый, шагыйрь, бабай, апа, сеңел,эне.**

**Безне**
**ң**
**гаилә**

Безнең гаилә.

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи-
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул
Хезмәте дә бар, өйне тычкан явыздан саклый ул.

*Габдулла Тукай.*

Тычкан-мышь

Явыз-злодей

# Шигырь буенча сорауларга җавап бир.

- “Безнең гаилә” шигырендә ничә кеше?
- Алар кемнәр?
- Песи ничәнче?
- Песи нәрсә эшли?
- Песинең эше нинди?

-Саша, синең гаиләдә ничә кеше бар?

-Минем гаиләдә 4 кеше бар.

-Әниең кайда эшли?

-Минем әнием  заводта эшли.



# Шүрәле



# Су анасы



# Бала белән күбәләк



# Кәҗә белән Сарык

# Өй эше

- “Безнең гаилә” шигырен яттан белергә.